БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«09» 06 2020 г. № 199

**Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасы максатларында матди - техник, медицина, азык-төлек һәм башка чаралар запаслары булдыру турында**

Муниципаль хокукый актларны гражданнар оборонасы өлкәсендә федераль һәм республика закон чыгару һәм башка норматив хокукый актлар, «Гражданнар оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын туплау, саклау һәм алардан файдалану турында» 2000 елның 27 апрелендәге 379 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Гражданнар оборонасы чараларын үтәүне тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләр төзүнең типлаштырылган тәртибен раслау турында» 2014 елның 18 декабрендәге 701 номерлы Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы боерыгы, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар тарафыннан туплана торган матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запаслары номенклатурасын һәм күләмнәрен билгеләү буенча 2017 елның 23 маендагы 2-4-71-11 номерлы методик тәкъдимнәре, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыру турында» 2014 елның 6 февралендәге 65 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 27 июнендәге 447 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары таләпләренә туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Расларга:

халыкны, штаттан тыш авария-коткару формированиеләрен һәм гражданнар оборонасы чараларын үтәүне тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләрне гражданнар оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыручы Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органы структуралары исемлеген (1 нче кушымта);

гражданнар оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларының номенклатурасын һәм күләмнәрен (2 нче кушымта).

2. Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисенә, үз вәкаләтләре кысаларында, Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар булдыру чараларын ел саен финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан оешма җитәкчеләренә 2020 елның 15 июненә кадәр гражданнар оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларының номенклатурасын һәм күләмен билгеләргә һәм әлеге запасларны булдырырга тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Балтач янгын сүндерү һәм коткару гарнизоны башлыгына методик ярдәм күрсәтүне һәм әлеге запасларны булдыруны контрольдә тотуны тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов